КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.05.2021 г.Казань № 98-П

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында урнашкан ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектлары территорияләренең чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында” 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында” 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы “Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре” карары нигезендә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары буларак, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын һәм аларның территорияләрен саклап калу һәм дәүләт саклавы максатларында боерык бирәм:

1. Әлеге боерыкка 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында урнашкан ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектлары территорияләре чикләрен расларга (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).
2. Әлеге боерыкка 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында урнашкан ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимын расларга (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).
3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Комитет рәисе урынбасары Н.В. Прохоровага йөкләргә.

Рәис И.Н. Гущин